Килешенгән:

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Чаллы ТВ» телерадиокомпаниясе
житәкчесенең радио буенча урынбасары
______________ Р.Р.Гатина
«___»________________ 2018 ел

Раслый:

Яр Чаллы шәһәре Үзәкләштерелгән
китапханәләр системасы директоры
______________ В.М.Гайнуллина
«___»________________ 2018 ел

# «Тел эчендә милләт җаны» дигән төбәкара шигъри бәйгенең НИГЕЗЛӘМӘСЕ

Яр Чаллы китапханәләр системасының 12нче санлы татар китапханәсе «Күңел» радиосы белән берлектә татар теле, татар әдәбиятының дәрәҗәсен арттыру максатыннан «Тел эчендә милләт җаны» дигән төбәкара шигъри бәйге игълан итә.

## 1.Бәйгенең максаты:

1.1.Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре хезмәткәрләренең иҗади эшчәнлекләрен үстерү, педагогик эшчәнлеген активлаштыру, алдынгы тәҗрибәне барлау һәм тарату;
1.2.Татар әдәбиятына карата мәхәббәт тәрбияләү, татар теленең дәрәҗәсен арттыру, мәдәниятебезне саклау, өйрәнү һәм үстерү.

## 2.Бәйгенең шартлары:

2.1.Бәйге мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре хезмәткәрләре арасында үткәрелә. Катнашучыларның яше чикләнмәгән.
2.2.Бәйгегә катнашу өчен теркәлү карточкасы тутырыла (Кушымта №1).
2.3.Катнашучы татар телендә яттан сәнгатьле итеп шигырь укый. Шигырь уку видеога төшерелеп, видеоязма китапханәнең электрон адресына җибәрелә: cbs_filial12@mail.ru. Видеоязманың форматы – wmv, mp4. Дәвамлыгы 5 минуттан артмаска тиеш. Бер катнашучыдан бер видеоязма кабул ителә.
2.4.Тәкъдим ителгән темаларны яктырту:
-татар теле;
– туган телебезне саклау;
– ватанпәрвәрлек.
2.5.Бәйгедә катнашу бәясе - 100 сум (Кушымта №2).
2.6.Теркәлү карточкасы, түләү квитанциясенең копиясе һәм видеоролик 15 январьдан алып 15 апрельгә кадәр кабул ителә. Эшләр билгеләнгән вакытта килеп җитмәсә, бәйгедә катнашмыйлар.

## 3. Бәйгене бәяләү:

3.1.Бәйгедә катнашучыларның татарча сәнгатьле итеп шигырь сөйләү осталыклары бәяләнә.
3.2.Чыгышның музыкаль бизәлеше һәм катнашучының милли киемдә булуы, эшкә иҗади якын килүе хуплана (өстәмә балл).
3.3. Башка милләт кешеләренең чыгышы аерым номинациядә бәяләнә.
3.4. Җиңүчеләр «Күңел» радиосы, Яр Чаллы китапханәләр системасының Дипломнары белән бүләкләнәләр.

3.5. Бәйгедә катнашучыларга электрон вариантта сертификатлар тапшырылачак.
3.6. Бәйгедә җиңүчеләр исемлеге Яр Чаллы китапханәләр системасының сайтында, 12 нче санлы татар китапханәсенең «В контакте» социаль челтәрендәге битенә урнаштырылачак.
3.7. Җиңүчеләрнең чыгышлары «Күңел» радиосы эфирында яңгыраячак.

**4.Бәйгене йомгаклау**

Бәйгене йомгаклау 25 апрель көнне Яр Чаллы китапханәләр системасының Яңа шәһәрнең 14/01 йортында урнашкан 12нче санлы татар китапханәсендә узачак. Белешмәләр өчен тел.35-33-86

**Жюри әгъзалары:**

1. В.А.Бадретдинова., Яр Чаллы шәһәре Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының методик бүлек мөдире;
2.Ә.З.Аксуева, Яр Чаллы шәһәре Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 12нче санлы татар китапханәсе җитәкчесе;
3.Г.Ф.Ямалеева, «Күңел» радиосының әйдәп баручы хезмәткәре;
4.З.М.Шакурова, Яр Чаллы шәһәре Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 12нче санлы татар китапханәсенең зурлар белән эшләү бүлеге мөдире.

**Кушымта №1.**

**ТЕРКӘЛҮ КАРТОЧКАСЫ**

1.Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме________________________________________________
_______________________________________________________________________________
2.Катнашучының яше_____________________________________________________
3.Тору урыны__________________________________________________________
4.Телефон_______________________________, E-mail____________________________
5.Эш урыны ______________________________________________________

**Кушымта №2.**

**РЕКВИЗИТЫ ДЛЯ ПЕРЕЧИСЛЕНИЯ ОРГАНИЗАЦИОННОГО ВЗНОСА**

МБУ «Централизованная библиотечная система»
ИНН/КПП 1650105517/ 165001001
Расч. счет 40701810692053000045
Корр.счет 30101810600000000805
БИК 049205001
Банк Отделение - НБ Республика Татарстан
Лицевой счет ЛБВ 30800866-ЦБС
Назначение платежа **На конкурс «Тел эчендә милләт җаны»**
ФИО участника ___________________________
**Библиотека-филиал №12**